Китаплар галәмендә// Көмеш кыңгырау. – 2025. - №7 (22 февраль). – Б. 2.

# Китаплар галәмендә

**10 елга якын Яр Чаллы шәһәренең 8нче балалар китапханәсендә «Беренче класслы укучы: укыйбыз, өйрәнәбез, иҗат итәбез!» программасы эшләп килә.**



*Лайсән Хәертдинова фотосы.*

Күптән түгел 21нче урта мәктәпнең башлангыч сыйныф укучылары белән очрашу узды. Китапханәчеләр «Китаплар галактикасы» дигән әдәби уен үткәрде. Балалар конкурсларда һәм викториналарда бик теләп катнашты.

«Кызыклы әдәбият» конкурсында яшь китап сөючеләр бергәләп карточкалардан әсәрләрнең исемнәрен төзеделәр һәм авторларын атадылар. «Табылдыклар бюросы» биремендә, төрле әкиятләрдән югалган әйберләрне табып, әдәби геройны таныдылар. Очрашу бик күңелле үтте. Һәр катнашучы үзенең сәләтен курсәтә алды.